ЦЕНТРАЛИЗОВАННАЯ РЕЛИГИОЗНАЯ ОРГАНИЗАЦИЯ
Духовное управление мусульман
Российской Федерации

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

# ГЫЙД ӘЛ-ӘДХА –
# КОРБАН БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН
## РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӨСЕЛМАННАРЫ
## ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ РӘИСЕ
# БАШ МӨФТИ ШӘЕХ
# РАВИЛ ГАЙНЕТДИН

# МӨРӘҖӘГАТЕ

Мәскәү
10 Зө-л-хиҗҗә, 1446 һиҗри ел
6 июнь, 2025 ел

بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

الحمد لله رب العالمين

والصلاة والسلام على رسولنا محمد

وعلى آله وصحبه أجمعين

أما بعد

*Рәхимле, шәфкатьле Аллаһ исеме белән!*

Җирдәге вә күк йөзендәге бар мәхлүкат тарафыннан макталучы, һәрнәрсәне Үз мәрхәмәте белән колачлаган галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһу Сөбханәһу вә Тәгаләгә мактау булсын! Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлламгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм Кыямәт көненә кадәр алар юлында булучыларга Раббыбызның рәхмәте ирешсен!

**Кадерле дин кардәшләрем!**

السلام عليكم ورحمة الله وبركاته

*Аллаһы Тәгаләдән иминлек, Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!*

Мөселман календаре буенча иң бөек көннәрнең берсе, хаҗның тәмамлануын билгеләүче Гыйд әл-Әдха — Корбан бәйрәме җитте. Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барыгызны да шушы бөек бәйрәм белән ихлас йөрәктән котлыйм!

Зө-л-хиҗҗә аеның бу көннәрендә хаҗилар Аллаһның әмеренә буйсынып, Аның каршында үз бурычын үти:

وَلِلّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ مَنِ اسْتَطَاعَ إِلَيْهِ سَبِيلاً

**«Һәм кешеләрнең Аллаһ каршында вазыйфасы Бәйткә (Кәгъбәгә) хаҗ кылудыр, әгәр алар моны үтәр хәлдә булсалар»**
(«Әлү Гыймран» сүрәсе, 93 нче аять).

Быел хаҗ кылырга киткән 25 мең ватандашыбыз арасында биш мең кеше «Хаҗ Кәрим-2025» хәйрия акциясе нигезендә, Сөләйман Әбүсәид улы Кәримовның матди ярдәме белән хаҗ кыла. Алар — махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның якын туганнары, СВО зонасында ярдәм итүче волонтерлар һәм хәрбиләргә рухи терәк булучы имамнар. Хаҗиларыбыз хаҗның һәр йоласын үтәп, өйләренә исән-имин әйләнеп кайтсын, Аллаһы Тәгалә хаҗларын һәм догаларын кабул итсен иде. Без шулай ук Аллаһы Раббыбыздан кардәшебез Сөләйман Кәримовның юмарт иганәсен кабул итүен һәм кардәшебезгә ике дөньяның да бәхетен һәм бәрәкәтен сорыйбыз.

Гыйд әл-Әдха — Корбан чалу бәйрәме, исламда аерым урын алып торучы пәйгамбәр — Ибраһим

галәйһиссәләм исеме белән бәйле.
Аллаһы Тәгалә Коръәндә аның турында
болай дигән:

إِنَّ إِبْرَاهِيمَ كَانَ أُمَّةً قَانِتًا لِلّهِ حَنِيفًا وَلَمْ يَكُ مِنَ الْمُشْرِكِينَ

**«Ибраһим, һичшиксез, имам, Аллаһка итәгать иткән, тәкъва һәм хәниф булды. Ул Аллаһка иптәш тотучы мөшрикләрдән булмады»**
(«Ән-Нәхл» сүрәсе, 120 аять).

Ибраһим пәйгамбәргә, сынау буларак, төшендә яраткан улын корбанга китерергә боерык бирелә. Улын яратуына карамастан, ул Аллаһы Тәгаләнең әмеренә буйсына, ә улы — Исмәгыйль галәйһиссәлам әтисенә теләктәшлек күрсәтә. Болар Ибраһим галәйһиссәлам белән Исмәгыйль галәйһиссәламнең Аллаһны чиксез яратуын күрсәтә.

يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ سَتَجِدُنِي إِن شَاء اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ

**«Әтием минем! Сиңа ничек боерылды — шулай эш ит һәм әгәр Аллаһ ихтыярында булса, син мине сабыр итүчеләрдән табарсың»**
(«Саффат» сүрәсе, 102 аять).

Ибраһим пәйгамбәр улын корбан итәргә ниятләп, яткыргач, ул шушы сүзләрне ишеткән:

يَا إِبْرَاهِيمُ قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا إِنَّا كَذَلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ

**«И Ибраһим! Син төшеңне раска чыгардың. Игелек кылучыларга Без шулай әҗерен бирәбез»** («Әс-Саффат» сүрәсе, 104–105 нче аятьләр).

Ибраһим пәйгамбәр Галәмнәрнең Раббысына үзендә булганның иң кыйммәтлесен бирергә әзер икәнлеген исбатлаган. Нәкъ менә шуңа күрә Аллаһы Тәгалә аңа пәйгамбәрелек биргән һәм нәселен дә пәйгамбәрләр белән дәвам иттергән:

وَإِذِ ابْتَلَى إِبْرَاهِيمَ رَبُّهُ بِكَلِمَاتٍ فَأَتَمَّهُنَّ قَالَ إِنِّي جَاعِلُكَ لِلنَّاسِ إِمَامًا قَالَ وَمِن ذُرِّيَّتِي قَالَ لاَ يَنَالُ عَهْدِي الظَّالِمِينَ

**«Раббысы Ибраһимны әмерләре белән сынаган иде һәм ул аларны үтәде. Аллаһ әйтте: «Мин сине кешеләргә имам итеп билгеләдем». Ибраһим сорады: «Минем нәселемне дә?» Аллаһ әйтте: «Минем вәгъдәм залимнәргә ирешмәс»**
(«Әл-Бәкара» сүрәсе, 124 нче аять).

Ибраһим галәйһиссәламнең тарихы безгә сынауларга әзер булырга һәм кискен мизгелдә дә Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатенә таянып, буйсынучанлык һәм түземлек күрсәтергә кирәклеге турында сабак бирә.

لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ إِنَّ
اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا إِنَّهُ
هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ

**«Аллаһының рәхмәтеннән өмет өзмәгез.**
**Хакыйкатьтә, Аллаһ бар гөнаһларны ярлыкаучы,**
**чөнки Ул — Гафу итүче һәм Рәхимле»**
(«Әз-Зүмәр» сүрәсе, 53 нче аять.)

***Кадерле дин кардәшләрем!***

Гыйд әл-Әдха — Корбан бәйрәме берничә көн дәвам итәчәк. Бу вакытта без туганлык җепләрен ныгыту максаты белән якыннарыбыз, туганнарыбыз янына барып, бүләкләр бирергә, кунак җыярга һәм аларны сыйларга тиеш, мондый гамәлләр өммәтебезнең бердәмлеген дә ныгытачак. Бу бәйрәм көннәрендә шулай ук тормышы җитеш булмаган, мәхәлләнең һәм дин кардәшләрнең игътибарына мохтаҗ кешеләрне дә онытмау бик мөһим. Корбан ите, бәйрәм сые, һичшиксез, мохтаҗларга, ялгызларга һәм ятимнәргә ирешергә тиеш.

فَإِذَا وَجَبَتْ جُنُوبُهَا فَكُلُوا مِنْهَا وَأَطْعِمُوا الْقَانِعَ وَالْمُعْتَرَّ
كَذَلِكَ سَخَّرْنَاهَا لَكُمْ لَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ

**«Корбан чалгач, аларның итен ашагыз һәм әздән дә канәгать**
**булганга да һәм фәкыйрьлектән оялып сораучыга да таратыгыз.**
**Без аларны сезгә буйсындырдык, шаять, шөкер итәрсез»**
(«Әл-Хәҗ» сүрәсе, 36 нче аять).

Зө-л-хиҗҗә аеның бу бәрәкәтле көннәрен ихлас догаларда, гыйбадәттә һәм игелекле гамәлләр белән үткәреп, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешергә насыйп булса! Фашизмны Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә, балаларының, оныкларының һәм оныкчыкларының киләчәге өчен башын салган, иң кыйммәтлесе — гомерен корбан иткәннәр өчен дога кылабыз. Аллаһы Тәгалә аларның фидакярлеген кабул итсен һәм аларны җәннәте белән бүләкләсен иде! Без Аллаһы Тәгаләдән кардәшләребезнең хаҗын кабул итүен, корбаннарыбызны, игелекле гамәлләребезне кабул итүен һәм йөрәкләребезгә ярату, шәфкать һәм мәрхәмәт хисләрен салуын, шулай ук Ватаныбызга һәм бар кешелек дөньясына тынычлык, уңышлар һәм иминлек бүләк итүе турында сорыйбыз!

Кадерле дин кардәшләрем, бәйрәм белән котлыйм сезне!

**Гыйд әл-Әдха мөбарәк!**

**والسلام عليكم ورحمة الله وبركاته**

**Аллаһы Тәгаләдән иминлек сезгә, Аның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!**

***Баш мөфти шәех Равил Гайнетдин,***
*Россия Федерациясе мөселманнары диния нәзарәте рәисе*